| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

20 июнь 2014 ел № 10-19/кс

Казань
шәһәре

***Эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызу хезмәтен күрсәткән ЯАҖ "Буа-Су каналы" өчен тарифларны билгеләү турында***

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында" 7 декабрь, 2011 ел, № 416-ФЗ Федераль законга, "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында" 13 май, 2013 ел, №406 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР бирә:

1. Әлеге карарның кушымтасына таянып, эчәргә яраклы су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган ЯАҖ "Буа-Су каналы" өчен эчәргә яраклы һәм ташландык суларны агызу тарифларын билгеләргә.

2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 1 августыннан 2014 елның 31 декаберенә кадәр үз көчендә була.

3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17 гыйнвар, 2013 ел, № 6 карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифны билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң, су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызу хезмәтен башкарган "Буа-Су каналы" ЯАҖнә 30 көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. "Эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызу хезмәте өчен тарифлар турында" 22.11.2013 № 10-47/кс Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карары кушымтасының 4 пунктындагы эчәргә яраклы су һәм ташландык суны агызу тарифын 2014 елның 1 августыннан үз көчен югалткан дип исәпләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы
тарифлар
буенча дәүләт комитетының
карарына кушымта
20 июнь 2014 ел № 10-19/кс

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызу хезмәтен башкарган ЯАЖ "Буа-Су каналы" өчен эчәргә яраклы су һәм ташландык суларны агызуга тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган оешма, муниципаль берәмлек исеме | Эчәргә яраклы суга тариф (берставкалы), сум/куб.м | Ташландык суны агызу тарифы (берставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | | 2014 елның 1 августыннан алып 2014 елның 31 декаберенә кадәр | 2014 елның 1 августыннан алып 2014 елның 31 декаберенә кадәр |
| | Буа муниципаль районы | | |
| 1 | ЯАЖ «Буа – Су каналы» | | |
| | Торак секторы кулланучылары (ӨБС исәпләнгән) | 26,69 | 37,78 |
| | Башка кулланучылар (ӨБС исәпкә алынмый) | 22,62 | 32,02 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештуры һәм җайга салу бүлеге